КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 апрель г.Казань № 270

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 23 апрель, 331 нче карары белән расланган Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 331 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 март, 234 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) белән расланган Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь

төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләренә, 13 пунктта «эшче» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин